**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчали авылында гражданнар җыены карары**

19 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчали авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчали авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Яңа Тинчәле авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү),

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, договор буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), хуҗасыз йорт хуҗалыкларын койма белән әйләндереп алу).»

3. Җыен нәтиҗәләрен Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчали авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Тинчәле авыл җирлеге башлыгы _________ Р.К. Мадышев

Гражданнар җыены секретаре _________ Г.Ш. Хәсәнова